**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4431**
**01.09.2022**

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль
программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге
5631 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5631 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 9 гыйнварындагы 4 номерлы, 2020 елның 26 июнендәге 3086 номерлы, 2020 елның 10 декабрендәге 6726 номерлы, 2021 елның 3 мартындагы 1440 номерлы, 2021 елның 1 апрелендәге 2238 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге 4694 номерлы, 2021 елның 10 сентябрендәге 5966 номерлы, 2021 елның 24 декабрендәге 8463 номерлы, 2022 елның 25 мартындагы 1618 номерлы, 2022 елның 10 июнендәге 3002 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә физик культура һәм спортны үстерү муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Физик культура» 1101 һәм «Массакүләм спорт» 1102 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 1 875 854,98 мең сум: 2020 ел - 547 453,5 мең сум, 2021 ел – 606 873,04 мең сум; 2022 ел – 721 528,44 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлында:

<table>
<tr><td rowspan="6">«Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары»</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары (мең сум)</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2020 ел</td><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>508 930,4</td><td>574 249,1</td><td>707 684,4</td><td>1 790 863,9</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>29 000,0</td><td>-</td><td>3 686,50</td><td>32 686,50</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>9 523,1</td><td>32 623,94</td><td>10 157,54</td><td>52 304,58</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>547 453,5</td><td>606 873,04</td><td>721 528,44</td><td>1 875 854,98</td></tr>
</table>

- 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 1 875 854,98 мең сум күләмендә бюджет акчаларын файдалану күздә тотыла: 2020 ел – 547 453,5 мең сум, 2021 ел – 606 873,04 мең сум; 2022 ел – 721 528,44 мең сум.»;

- 8 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 1 сентябрендәге
4431 номерлы карарына
кушымта

8 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә физик культура һәм спортны үстерү» программасын чаралар буенча финанслау

| № т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның зурлыгы | | | | Чыганакны күрсәтеп, финанслау мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Программаның максаты – җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү | | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру | | | | | | | | | | | |
| 1. | Физик культура һәм массакүләм спортны үстерү мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актларны эшләү һәм раслау, халыкның төрле яшь төркемнәре арасында физкультура - сәламәтләндерү, комплекслы, спорт чараларын үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык өлеше, гомуми халык саны буенча, % | 47,9 | 49,7 | 50,8 | 51,5 | | | |
| 2. | Сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр һәм инвалидлар арасында шәһәр физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы чаралар, фестивальләр, спорт бәйрәмнәре үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өлеше, халыкның әлеге категориясенең гомуми саны буенча, % | 19 | 19,5 | 20,5 | 21 | | | |
| 3. | Халыкның төрле яшь төркемнәре арасында» «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын популярлаштыруга юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм уздыру | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән халык өлеше, ГТО үтәүдә | 35 | 35,5 | 36,5 | 37 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | катнашкан гомуми халык саны буенча, % | | | | | | | |
| 4. | Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар үткәрү<br>Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча массакүләм спорт ярышлары үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар саны, берәмлек | 20 | 20 | 20 | 20 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 2344,1 | 1455,7 | 1486,4 |
| 5. | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында спорт төрләре буенча ярышлар, милли халык уеннары һәм ярышлары үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында ярышлар саны, берәмлек | 27 | | 27 | 27 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 0,0 | 936,8 | 1000,0 |
| 6. | «Спорт сөюче Чаллы» хезмәт ияләре спартакиадасы үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, администрации районов Исполнительного комитета | ел саен | «Спорт сөюче Чаллы» спартакиадасы кысаларында спорт төрләре буенча ярышлар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 34,8 | 0,0 | 49,5 |
| 7. | «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогы»на ярышлар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме кубогы»на ярышлар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 30,4 | 0,0 | 31,8 |
| Бурычның исеме: Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру | | | | | | | | | | | |
| 8. | Шәһәр Хакиме стипендияләре түләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Хаким стипендиясе алган балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше | 10 | 10 | 10 | 10 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 120,0 | 120,0 | 120,0 |
| 9. | Югары һөнәри осталык өчен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Хаким премиясен | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт | ел саен | Хаким премиясе алган физкультура-спорт учреждениеләренең | 15 | 15 | 15 | 15 | Муниципаль бюджет | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гамәлгә кую | идарәсе | | хезмәткәрләре саны, кеше | | | | | 390,6 | 390,6 | 390,6 |
| 10. | Халыкара һәм Россия ярышларында югары спорт казанышлары өчен спортчыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Россия, Европа, дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарында, Бөтендөнья Универсиадада бүләкләнгән җиңүчеләр һәм призерлар саны, кеше | 40 | 11 | 20 | 20 | Муниципаль бюджет<br>624,9 | 1 042,5 | 1 233,9 |
| 11. | Түбәндәге спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программасын гамәлгә ашыру: баскетбол, волейбол, җиңел атлетика, спорт ориентлашуы, дзюдо, каратэ киокусинкай, кикбоксинг, йөзү, синхрон йөзү, нәфис гимнастика, велоспорт, спорт гимнастикасы, теннис, тимераякта узышу спорты, футбол, велоспорт (шоссе), регби, билбаулы көрәш, грек-рим көрәше, армреслинг, көрәш, йөзү, тхэквондо, күп стильдәге каратэ, батутта сикерү, АКД, спорт акробатикасы, бокс, авыр атлетика, чаңгы узышлары, бию спорты, ат спорты, спорт туризмы, өстәл теннисы, бадминтон, җилкәнле спорт, фехтование, пауэрлифтинг, алкалы хоккей, тимераякта фигуралы шуу, шахмат | 17<br>физик культура һәм спорт муниципаль учреждениесе | ел саен | Гомуми тренерлар санынннан югары һөнәри белемле тренер кадрлар өлеше, % | 92 | 93 | 94 | 95 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | Хезмәт күрсәтү сыйфатына карап төркемнәрнең факттагы тулылыгы, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 484365,7 | 574249, | 702260,72 |
| | | | | Конкурсларда, фестивальләрдә, күргәзмәләрдә, ярышларда катнашучы шөгыльләнүчеләр саны, гомуми укучылар саны буенча, %, шул исәптән:<br>- муниципаль;<br>- региональ;<br>-федераль, халыкара | 20<br>10<br>1 | 30<br>20<br>1 | 30<br>20<br>1 | 30<br>20<br>1 | | | |
| | | | | Укыту программаларының үтәлү проценты, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | | | Контингент сакланышы, % | 88 | 88 | 88 | 88 | | | |
| 12. | Муниципаль спорт мәктәпләре хоккей командаларының хоккей буенча Татарстан | 1<br>физик культура һәм | 2020-2022 еллар | Муниципаль спорт мәктәпләренең хоккей | | 80 | 80 | 80 | Республика бюджеты | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Республикасы Чемпионатында һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында катнашуы | спорт муниципаль учреждениесе | | командалары катнашкан хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионаты һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионаты уеннарының саны | | | | | 1 224,4 | 1 492,3 | 2 519,0 |
| 13. | Спорт мәктәпләренең спорт инвентаре, җиһазлар, экипировка белән җиһазландырылуы | 16 физик культура һәм спорт муниципаль учреждениесе | 2020-2022 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга субсидия алган муниципаль учреждениеләр саны | | 16 | 16 | 16 | Республика бюджеты<br>4090,9 | <br>3 320,2 | <br>2380,5 |
| 14. | Спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазлары һәм инвентарь сатып алу буенча чараларны тормышка ашыру | 7 физик культура һәм спорт муниципаль учреждениесе | 2022 ел | Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга субсидия алган муниципаль учреждениеләр саны | | | | 7 | Федераль бюджет<br><br>Республика бюджеты<br><br>Муниципаль бюджет | | <br>3686,50<br><br>864,735<br><br>1067,575 |
| 15. | Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чаралары үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру | 15 физик культура һәм спорт муниципаль учреждениесе | 2020-2022 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларында спортчылар катнашуга субсидия алган муниципаль учреждениеләр саны | | 1 | 1 | 15 | Республика бюджеты<br>992,0 | <br>2290,3 | <br>4393,3 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет<br>10,0 | <br>22,9 | <br>43,9 |
| 16. | Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру, муниципаль бурычны үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә | 3<br>физик культура һәм спорт муниципаль учреждениесе | 2020-2021 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль учреждениеләр саны | | 1 | 2 | | Республика бюджеты<br>3225,67<br>Муниципаль бюджет | <br>24643,14<br><br>246,43 | |
| 17. | Заманча спорт-сәламәтләндерү комплексы, махсуслаштырылган спорт корылмасы төзү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2020 ел | Дәүләти-шәхси партнерлык катнашында төзелгән спорт-сәламәтләндерү комплекслары, махсуслаштырылган спорт корылмалары, берәмлек | | 1 | | | Федераль бюджет<br>29 000<br>Муниципаль бюджет<br>21 000 | | |
| 18. | Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль йөкләмәсен үтәү максатларында спорт объектларының террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле | 4<br>физик культура һәм спорт муниципаль учреждениесе | 2021 ел | Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, субсидия алган муниципаль учреждениеләр саны | | | 4 | | Республика бюджеты<br><br>Муниципаль бюджет | <br>878,0<br><br>8,78 | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Абдуллина